| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ**
**«19» май 2023 ел**

**КАРАР**
**№ 115**

Норлат авыл җирлеге Советының 2013 елның 13 ноябрендәге 127 номерлы карары белән расланган (Норлат авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 августындагы 176 номерлы, 2018 елның 17 декабрендәге, 166 номерлы, 2019 елның 12 ноябрендәге 202 номерлы, 2021 елның 04 июнендәге 36 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына бюджет процессын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Норлат авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Норлат авыл җирлеге Советының 2013 елның 13 ноябрендәге 127 номерлы карары белән расланган (Норлат авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 августындагы 176 номерлы, 2018 елның 17 декабрендәге, 166 номерлы, 2019 елның 12 ноябрендәге 202 номерлы, 2021 елның 04 июнендәге 36 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 статьясындагы 2 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Раисы» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 39 нчы статьяның 2 нче пунктының өченче абзацында «бюджет йөкләмәләре» сүзләреннән соң «һәм элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә» сүзләр белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл

җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.

**Норлат авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.М.Саттаров**